КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 ноябрь г.Казань № 1116

2017 – 2030 елларга Татарстан Республикасының мәдәни мирасын саклау стратегиясен раслау турында

Татарстан Республикасы территориясендә тарихый-мәдәни мирасны саклау мәсьәләләрен нәтиҗәле хәл итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2017 – 2030 елларга Татарстан Республикасының мәдәни мирасын саклау стратегиясен (алга таба – Стратегия) расларга.
2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына мәдәни мирасны саклау мәсьәләләрендә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләгәндә һәм тормышка ашырганда Стратегиягә таянып эш итәргә.
3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мәдәни мирасны саклау мәсьәләләрен хәл иткәндә Стратегия нигезләмәләренә таянып эш итүне тәкъдим итәргә.
4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин